**Казан шәһәре Башкарма комитетының**
**2026 елның 1 сентябрендәге 3063 номерлы карары**

# Казан шәһәре Башкарма комитетының 2011 елның 9 мартындагы 933 номерлы карары белән расланган «Җиңү паркы» районы территориясен планлаштыру проектына үзгәрешләр кертү турында

Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 42, 45, 46 статьяларына таянып, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2024 елның 2 февралендәге 112 номерлы «Федераль башкарма хакимиятнең вәкаләтле органнары, вәкаләтле Россия Федерациясе субъектларының башкарма органнары һәм җирле үзидарә органнары карарлары нигезендә әзерләнә торган территорияне планлаштыру документларын әзерләү, территорияне планлаштыру документларын раслау турында карар кабул итү, мондый документларга үзгәрешләр кертү, мондый документларны яки аның аерым өлешләрен гамәлдән чыгару, мондый документларның аерым өлешләрен кулланылырга тиеш түгел дип тану, шулай ук федераль һәм төбәк әһәмиятендәге тарихи җирлекләр территорияләренә карата территорияне планлаштыру проектын әзерләү һәм раслау кагыйдәләрен раслау турында»гы карары нигезендә **карар бирәм**:

1. Казан шәһәре Башкарма комитетының 2011 елның 9 мартындагы 933 номерлы карары белән расланган «Җиңү паркы» районы территориясен планлаштыру проектына, әлеге карарга кушымта нигезендә планлаштыру проектының аерым өлешләрен раслап, үзгәрешләр кертергә.

2. Әлеге карарны, билгеләнә торган кызыл линияләрнең характерлы нокталары координаталары исемлегеннән һәм борылыш нокталары координаталары белән кызыл линияләр күрсәтелгән территорияне планлаштыру сызымыннан (хезмәт урынында файдалану өчен материаллар) кала, «Муниципаль хокукый актлар һәм башка рәсми мәгълүмат» челтәр

басмасында (www.docskzn.ru) бастырырга, Казан шәһәре җирле үзидарә органнарының рәсми порталында (www.kzn.ru) һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (www.pravo.tatarstan.ru) урнаштырырга.

3. Әлеге карар «Муниципаль хокукый актлар һәм башка рәсми мәгълүмат» челтәр басмасында (www.docskzn.ru) рәсми басылып чыкканнан соң гамәлгә керә дип билгеләргә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Казан шәһәре Башкарма комитеты Җитәкчесенең беренче урынбасары А.Р.Нигъмәтҗановка йөкләргә.

**Җитәкче** **Р.Г.Гафаров**

Казан шәһәре
Башкарма комитетының
2026 елның 1 сентябрендәге
3063 номерлы карарына
кушымта

**Казан шәһәре Башкарма комитетының**
**2011 елның 9 мартындагы**
**933 номерлы карары белән расланган**
**«Җиңү паркы» районы территориясен**
**планлаштыру проектына кертелә торган үзгәрешләр**

1. «Җиңү паркы» районы территориясен планлаштыру проектына икенче абзацтан соң түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«- территорияне план буенча үстерү чираты турында нигезләмә;».

2. «Җиңү паркы» районы территориясен планлаштыру проектында өченче абзацны төшереп калдырырга.

3. Җирле әһәмияттәге капиталь төзелеш объектларын урнаштыру, территорияне план буенча үстерү характеристикалары, территорияне үстерү өчен кирәкле социаль, транспорт хезмәте күрсәтү һәм инженерлык-техник яктан тәэмин итү системаларын үстерү характеристикалары турында нигезләмәгә түбәндәге эчтәлекле 8 бүлек өстәргә:

«8. Җиңү паркыннан төньяк-көнбатыштарак, Бондаренко, Маршал Чуйков урамнары киселешендә территорияне план буенча үстерү характеристикалары.

8.1. Проектлаштыру территориясе урнашкан урын турында мәгълүмат.

Территория Татарстан Республикасы Казан шәһәре муниципаль берәмлеге шәһәр округының Яңа Савин районында урнашкан.

Территорияне планлаштыру проектының (алга таба – Проект) чикләре:

- төньяктан – Маршал Чуйков урамы;

- төньяк-көнчыгыштан – «Таиф-НК автомобильләргә ягулык салу станциясе» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыятенең автомобильләргә ягулык салу станциясе;

- көнчыгыштан – «Искәндәр» футбол-регби манежы;

- көньяктан – «Ватан» спорт комплексы;

- көнбатыштан – Бондаренко урамы.

Казан шәһәр округының Генераль планы буенча территория ID 2143

(индекс 123) функциональ зонасы чикләренә керә, территорияне планлаштыру проектында табигать-рекреация комплексы чикләре билгеләнә.

Фактта карап тикшерелә торган территориянең мәйданы – 3,46 га.

Территориядә торак булмаган билгеләнештәге кертеп-кушып төзелгән биналар, аңа хезмәт күрсәтү өчен кирәкле транспорт һәм инженерлык инфраструктурасы объектлары булган күпкатлы (18 катка кадәр) торак төзелеше планлаштырыла,.

Россия Төзелеш министрлыгының 2017 елның 25 апрелендәге 738/пр номерлы әмере нигезендә планлаштыру структурасы элементы – 2,61 га мәйданлы торак квартал (К-1) бүлеп чыгарыла.

Халыкның исәпләнгән саны (бер кешегә 30 кв.м исәбеннән) – 2000 кеше. Территориядә федераль, төбәк, җирле әһәмияттәге объектлар юк.

Планлаштырыла торган торак фондының гомуми мәйданы (фатирларның гомуми мәйданы) – 60,0 мең кв. м. Күпфатирлы торак йортлар составында кертеп-кушып төзелгән торак булмаган биналарның гомуми мәйданы – 5,36 мең кв. м.

Зоналар территориясен проектлау территориясе чикләрендә файдалануның проект балансы (К-1) 8.1.1 таблицасында бирелгән.

8.1.1 таблица

**Территориядән файдалануның проект балансы**

| Зона номеры | Капиталь төзелеш объектларын план буенча урнаштыру зоналары төре | Мәйдан, га | Мәйдан өлеше, % |
|---|---|---|---|
| 1 | Күпкатлы торак төзелешен план буенча урнаштыру зонасы | 2,61 | 75,4 |
| 2 | Урам-юл челтәрен урнаштыру зонасы | 0,85 | 24,6 |
| **БАРЛЫГЫ** | | 3,46 | 100 |

8.2. Территориядә төзелеш тыгызлыгы һәм параметрлары, торак, җитештерү, иҗтимагый-эшлекле һәм башка билгеләнештәге капиталь төзелеш объектлары характеристикалары 8.2.1 таблицасында күрсәтелгән.

8.2.1 таблица

**Территориядә төзелеш тыгызлыгы һәм параметрлары,
капиталь төзелеш объектлары характеристикалары**

| е планлаштыру сызымында зона номеры | Капиталь төзелеш объектларын урнаштыру зонасы төре | Урнаштыру зонасы мәйданы (гектар) | ән файдалану төрләре кодлары | Объектларның әһәмияте (м – җирле) | орак фондының максималь гомуми мәйданы (мең кв. м) | Капиталь төзелеш объектларының максималь катлар саны | Торак фондының (фатирларның) максималь тыгызлыгы (мең кв. м/гектар) | Иҗтимагый билгеләнештәге кертеп-кушып төзелгән биналарның гомуми мәйданы (кв. | Урнаштырыла торган объектлар турында мәгълүмат |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| 1 | Күпкатлы торак төзелешне план буенча урнаштыру зонасы | 2,61 | 2.6, 2.7.1, 3.1.1, 3.2.3, 3.3, 3.6.1, 4.1, 4.4, 4.5, 4.6, 4.9.2, 5.1.2, 5.1.3, 8.3 | Билгеләнмә гән | 60,0 | 18 | 22,99 | 5360 | Торак булмаган билгеләнештәге кертеп-кушып төзелгән биналар булган күпкатлы торак төзелеше |
| 2 | Урам-юл челтәрен урнаштыру зонасы | 0,85 | Билгеләнмә гән | Билге ләнмә гән | 0 | Билге ләнмә гән | - | - | Гамәл дәге урам-юл төзеле ше |

Искәрмә: күпкатлы торак төзелешен план буенча урнаштыру зонасының төньяк-көнчыгыш өлешендә, автомобильләргә ягулык (газ) салу станциясеннән чикләүләр алынгач (яисә тиешле объектларны урнаштыру мөмкинлеге нигезләнгәннән соң), кешеләр күпләп була торган урыннарны, Ф1-Ф4 функциональ янгын куркынычлыгы классларына караган биналарны һәм корылмаларны урнаштыру рөхсәт ителә.

Объектлардан санитар-сак зоналарын билгеләү кирәк булган очракта, территорияне планлаштыру буенча документлары карарларын исәпкә алырга һәм күпкатлы торак төзелешен планлаштырыла торган зона өчен хокуклар чикләүне бетерергә кирәк.

8.3. Капиталь төзелеш объектларын төзүнең, реконструкцияләүнең рөхсәт ителгән чик параметрлары.

Күпкатлы торак төзелеше зонасы чикләрендәге җир кишәрлекләре өчен, шул исәптән яңа ясала торган җир кишәрлекләре өчен, капиталь төзелеш объектларын төзүнең, реконструкцияләүнең түбәндәге чик параметрлары билгеләнә:

– биналарны, корылмаларны урнаштыру мөмкинлеген билгеләү максатыннан җир кишәрлегенең алгы, ян һәм арткы чикләреннән минималь ераклык (транспортта керү (чыгу) урыннарын, инженерлык җиһазларын һәм эвакуация буенча чыгу юлларын үз эченә алган җир асты төзелешеннән тыш) төзелешне җайга салу сызымнарында чагылыш тапкан линияләр буенча билгеләнә, төзелешне җайга салу линиясе булмаганда, нульгә тигез итеп билгеләнә. Җир кишәрлекләре чикләреннән минималь ераклыклар өченче затларның мәнфәгатьләрен, техник регламентларны исәпкә алырга тиеш. Транспортта керү (чыгу), инженерлык җиһазлары һәм эвакуация буенча чыгу юлларын үз эченә алган җир асты төзелеше өчен минималь калдырылган аралар билгеләнми. Төзелешне җайга салу линияләре, транспортта керү (чыгу) юлларын, инженерлык җиһазларын һәм эвакуация буенча чыгу юлларын да кертеп, җир асты төзелешенә кагылмый;

- җир кишәрлеген төзүнең (торак фондының) максималь тыгызлыгы – 23,35 мең кв. м/га;

- гомуми файдалану территориясенә чыкмый торган беренче кат фасады озынлыгының яки төзелешне җайга салу һәм иҗтимагый функциягә файдалану линияләренең максималь проценты – 80;

- гомуми файдаланудагы территориягә чыга торган беренче кат фасады озынлыгының кызыл линияләр яки төзелешне җайга салу һәм иҗтимагый функция өчен файдалану линияләре белән бүленгән минималь проценты – 80;

- җир кишәрлеге чикләрендә урнаштырылырга тиешле машина урыннарының минималь саны – 621.

8.4. Инженерлык (коммуналь) инфраструктурасы объектларына характеристика.

8.4.1 таблица

**Инженерлык (коммуналь) инфраструктурасы объектларына характеристика**

| Аталышы | Характеристикалар* | Чаралар, тоташу нокталары* |
| --- | --- | --- |
| Су белән тәэмин итү | «Водоканал» муниципаль унитар предприятиесе челтәрләренә тоташтырылган үзәкләштерелгән су белән тәэмин итү системасы.<br>Су белән тәэмин итүнең техник мөмкинлеге – 820,6 куб.м/тәүлек. | Тоташу ноктасы – Маршал Чуйков урамындагы Ø 400 мм лы һәм Бондаренко урамындагы Ø 500 мм лы суүткәргеч.<br>Чара:<br>- тоташу ноктасыннан алып проектлау чикләрендә планлаштырыла торган төзелешкә кадәр су белән тәэмин итүнең үткәргеч челтәрләрен төзү |
| Су чыгару. Хуҗалык-көнкүреш канализациясе | «Водоканал» муниципаль унитар предприятиесе челтәренә үзәкләштерелгән су чыгару. Су чыгаруның техник мөмкинлеге –<br>506,9 куб.м/тәүлек. | Тоташу ноктасы – Маршал Чуйков урамындагы Ø 500 мм лы канализация коллекторы яисә Ямашев проспектындагы Ø 800 мм лы канализация коллекторы.<br>Чара:<br>- планлаштырыла торган төзелештән алып тоташтыру ноктасына кадәр су агызу челтәрләрен төзү;<br>- Маршал Чуйков урамындагы Ø 500 мм лы канализация коллекторын реконструкцияләү |
| Яңгыр канали-зациясе | Яңгыр һәм кар суларын ябык яңгыр канализациясе челтәре ярдәмендә үзәкләштерелгән рәвештә агызу.<br>Агынтыларны чистарту – планлаштырыла торган шәһәр өстендәге агынты суларны чистарту корылмаларында.<br>Яңгыр челтәрләрен гидравлик исәпләү өчен яңгыр суларының күләме – 154,83 л/сек. | Тоташу ноктасы – Маршал Чуйков урамындагы яңгыр канализациясе челтәре.<br>Чара:<br>- тоташу ноктасына ябык типтагы читкә җибәрә торган челтәрләр төзү;<br>- Маршал Чуйков урамындагы яңгыр канализациясе коллекторына чистартылган агынтыларны агызып, локаль чистарту корылмасын урнаштыру |
| Электр энергиясен куллану | Тоташтыру планлаштырыла торган гомуми егәрлек – 2238 кВт тан артык түгел, көчәнеш дәрәҗәсе – 0,4 кВ, ышанычлылык категориясе – II һәм III | Туклану үзәге – «Савиново» подстанциясе, планлаштырыла торган ТП. Бүлү челтәрләренең көчәнеше – 10 кВ һәм 0,4 кВ.<br>Чаралар:<br>- трансформатор подстанцияләре төзү (ике объект);<br>- гамәлдәге ТП-2574 белән яңа ТП бәйләнеше;<br>- ТП дан кулланучыларга кадәр 0,4 кВ көчәнешле бүлеп бирү челтәрләрен төзү |

| Аталышы | Характеристикалар* | Чаралар, тоташу нокталары* |
|---|---|---|
| Җылылык белән тәэмин итү | 5,46 Гкал/сәг. егәрлекле үзәкләштерелгән җылылык челтәрләреннән җылылык белән тәэмин итүнең техник мөмкинлеге | Җылылык белән тәэмин итү челтәрләренә тоташу ноктасы – Бондаренко урамындагы җылылык белән тәэмин итү челтәрләре (ике җылылык камерасы).<br>Чара:<br>- Бондаренко урамындагы җылылык камераларын үзгәртеп кору (җылылык камераларының берсен күчерү планлаштырыла);<br>- гамәлдәге җылылык белән тәэмин итү челтәрләрен Бондаренко урамы буенча Ø 300 мм га күчерү;<br>- планлаштырыла торган төзелешкә тоташу нокталарыннан җылылык челтәрләре төзү;<br>- бикләвеч арматура, исәпләү җайланмалары һәм башка җиһазларны урнаштыру өчен җылылык узеллары төзү |
| Элемтә | Планлаштырыла торган объектларны, кимендә өч хезмәт күрсәтүчене тоташтыру мөмкинлеге булган кабель канализациясе салу юлы белән элемтә челтәрләре белән тәэмин итү | Тоташу ноктасы – Маршал Чуйков урамы, 6Б янындагы кабель коесы (корп. 1).<br>Чара:<br>- тоташтыру ноктасыннан алып проектлау территориясенә кадәр кабель канализациясе төзү;<br>- телекоммуникация шкафлары урнаштыру;<br>- телекоммуникация шкафларыннан алып кулланучыларга кадәр аз токлы челтәрләрне тоташтыру;<br>- төзелеш зонасына керә торган инженерлык челтәрләрен коридорларга күчерү яки гамәлдәге элемтә челтәрләрен сүтү |

* Инженерлык инфраструктурасы объектларының күрсәткечләре, тоташу нокталары, саны һәм урнашу урыны проектлауның киләсе стадияләрендә төгәлләштерелергә мөмкин, шул ук вакытта территорияне планлаштыру документларына үзгәрешләр кертү таләп ителми.

## 8.5. Транспорт инфраструктурасы объектларына характеристика.

Территория район әһәмиятендәге Бондаренко һәм Маршал Чуйков магистраль урамнары белән формалаштырылган гамәлдәге урам-юл челтәре белән тәэмин ителгән.

Проект транспорт белән барып җитү мөмкинлеген һәм гамәлдәге урам-юл

челтәре белән үзара бәйләнешне тәэмин итә. Территориягә Бондаренко урамыннан чыгу юллары планлаштырылган.

Таблица 8.5.1

**Транспорт чараларын саклау һәм кую урыннарына ихтыяҗ һәм аларны план буенча урнаштыру**

| Территорияне планлаштыру сызымында зона номеры | Торак йортларда яшәүчеләрнең транспорт чараларын даими саклау өчен кирәк булган урыннар санына ихтыяҗ | Торак йортларга килүчеләр өчен транспорт чараларын кую урыннарына булган ихтыяҗ | Күпфатирлы торак йортларның кертеп-кушып төзелгән биналары өчен транспорт чараларын кую урыннарына булган ихтыяҗ | Объект янындагы транспорт чараларын кую урыннарында машина урыннарына булган ихтыяҗ | Капиталь төзелеш объектларын урнаштыру зоналары чикләрендә урнаштырылырга тиешле машина урыннарының минималь саны | Капиталь төзелеш объектларын урнаштыру зонасы өчен транспорт чарасын кую урыннарын башкача урнаштыру |
|---|---|---|---|---|---|---|
| 1 | 600 | 108 | 67 | - | 621 | Урам-юл челтәренең кызыл линияләрендәге муниципаль парковкаларда 160 машина урыны |
| **БАРЛЫГЫ** | **781** | | | **781** | | |

Искәрмә:

1. Күпкатлы торак төзелешен планлаштырыла торган зона чикләрендә парковка урыннарын урнаштыру ысулы һәм урыны проектлауның киләсе стадияләрендә төгәлләштерелергә мөмкин.
2. Күрсәткечләр (фатирларның гомуми мәйданы, торак булмаган урыннарның гомуми мәйданы) кимегән очракта, парковка урыннарына һәм инфраструктураның башка объектларына булган ихтыяҗ күрсәткечләре, Казан шәһәренең шәһәр төзелешен проектлаштыруның җирле нормативлары таләпләреннән чыгып, яңадан исәпләнә.
3. Гомуми ихтыяҗда электр энергиясен җыю станцияләре өчен парковка урыннарына – 6 машина урынына ихтыяҗ исәпкә алынды.

Планлаштырыла торган торак төзелеше өчен 160 машина урынына исәпләнгән парковка урыннары урам-юл челтәренең муниципаль парковкаларында урнаштырыла:

- Бондаренко урамындагы планлаштырылган муниципаль парковкада – 45 парковка урыны,

- гамәлдәге муниципаль парковкаларда – 115 парковка урыны, шул исәптән:

– 21 урын – Короленко урамындагы 408 номерлы парковка зонасында;

– 19 урын –Восстание урамындагы 211 номерлы парковка зонасында;

– 58 урын – Короленко урамындагы 205 номерлы парковка зонасында;

– 9 урын – Волгоград урамындагы 196 номерлы парковка зонасында;

- 8 урын –Бондаренко урамындагы 195 номерлы парковка зонасында.

8.6. Социаль инфраструктура объектларына характеристика 8.6.1 таблицада бирелгән.

8.6.1 таблица

**Социаль инфраструктура объектларының сыйдырышлылыгына ихтыяҗ**

| Территорияне планлаштыру сызымында торак төзелешен план буенча урнаштыру зонасы номеры | Мәктәпкәчә мәгариф учреждениеләрендә урыннарга ихтыяҗ, урын | Гомуми белем бирү учреждениеләрендә урыннарга ихтыяҗ, урын | Амбулатор-поликлиника оешмаларында бер сменага килү саны буенча ихтыяҗ, бер сменага килүчеләр саны |
|---|---|---|---|
| 1 | 144 | 282 | 40 |

Күпкатлы торак төзелешенең планлаштырыла торган зонасы өчен мәктәпкәчә мәгариф, гомуми белем бирү оешмаларында урыннарның исәпләнгән санына ихтыяҗ гамәлдәге мәгариф объектларында барып җитәрлек норматив радиуста тәэмин ителә.

Өстәмә белем бирү объектларына ихтыяҗ булган объектларда, күпфатирлы торак йортларның торак булмаган биналары составында барып җитәрлек радиуста тәэмин ителә.

Сәламәтлек саклау объектларында тәэмин ителеш:

- өлкәннәр өчен – «10 номерлы шәһәр поликлиникасы» дәүләт автоном сәламәтлек саклау учреждениесе, Бондаренко урамы, 4а йорт;

- балалар өчен – «7 номерлы шәһәр балалар поликлиникасы» дәүләт автоном сәламәтлек саклау учреждениесе, Ямашев проспекты, 48 йорт.

Территориянең хезмәт күрсәтү радиусында ашыгыч ярдәм хезмәтләре белән тәэмин ителеше:

- Россия Гадәттән тыш хәлләр министрлыгының Татарстан Республикасы буенча Баш идарәсенең Дәүләт янгынга каршы хезмәте федераль янгынга каршы хезмәтенең 7 нче янгын-коткару отрядының зур янгыннарны сүндерү буенча 48 нче махсуслаштырылган янгын-коткару часте (Адоратский урамы, 20);

- 8 номерлы ашыгыч медицина ярдәме подстанциясе (Адоратский урамы, 29В) ;

- полиция участок бүлеге (Волгоград урамы, 37).

Башка хезмәт күрсәтү объектларына ихтыяҗ гамәлдәге объектларда, шулай ук күпфатирлы торак йортларның төзелгән бизнаалары составында проектлауга йөкләмә буенча тәэмин ителә.

8.7. Табигать-рекреация комплексы.

Территория «Җиңү паркы» җирле әһәмияттәге махсус саклanучы табигать территориясе янәшәсендә урнашкан.


Казан шәһәр округының Генераль планы материаллары (табигать-рекреация комплексы картасы) нигезендә территориядә табигать-рекреация комплексының чикләре территорияне планлаштыру проектында билгеләнә. Территория чикләрендә гомуми файдаланудагы яшелләндерелгән территорияләрнең мәйданы – 0,15 га».

4. «Җиңү паркы» районы территориясен планлаштыру проектына түбәндәге эчтәлекле I(1) бүлек өстәргә:

«I(1). Территорияне план буенча үстерү чираты турында нигезләмә

Территорияне план буенча үстерүнең 1 нче чираты каралган (1 рәсем).

Гамәлгә ашыру шартлары: һәр күпфатирлы торак йортны файдалануга тапшырганда, халыкның җиңел автомобильләрен даими саклау өчен парковка урыннарын тиешле файдалануга тапшырыла торган объект өчен нормативтан ким булмаган күләмдә тәэмин итү зарур.




1 рәсем – территорияне план буенча үстерү чираты схемасы.

I(1).1 таблица

**Чараларны үтәү этаплары һәм аларны башкаруның максималь вакытлары**

<table>
<tr><th rowspan="2">Капиталь төзелеш объектлары төрләре</th><th rowspan="2">Объектлар</th><th colspan="3">Максималь вакытлар*, еллар</th></tr>
<tr><th>Архитектура-төзелеш ягыннан проектлау (җир кишәрлеген ясау/архитектура ягыннан проектлау/экспертиза)</th><th>Капиталь төзелеш объектларын сүтү (капиталь төзелешнең башка объектларын төзү, реконструкцияләү өчен капиталь төзелеш объектларын, аларның өлешләрен сүтү кирәк булган очракта)</th><th>Төзү</th></tr>
<tr><td>Торак билгеләнешендә</td><td>Торак булмаган билгеләнештәге кертеп- кушып төзелгән биналар белән күпкатлы торак төзелеше</td><td rowspan="3">2029</td><td rowspan="3">-</td><td rowspan="3">2036</td></tr>
<tr><td>Транспорт инфраструктурасы</td><td>Муниципаль парковка</td></tr>
<tr><td>Инженерлык инфраструктурасы</td><td>Трансформатор подстанциясе, яңгыр канализациясенең чистарту корылмалары</td></tr>
<tr><td>Башка билгеләнештә</td><td>Планлаштырыла торган төзелеш участокларында капиталь төзелеш объектлары</td><td>-</td><td>2033</td><td>-</td></tr>
</table>

* Төзелешкә рөхсәттә төгәлләштерелергә мөмкин».

5. Кызыл линияләр, юлларны, урамнарны билгеләүче линияләр, элемтә линияләре, инженерлык һәм транспорт инфраструктурасы объектлары күрсәтелгән территорияне планлаштыру сызымын гамәлдән чыккан дип танырга.


6. Кызыл линияләр, юлларны, урамнарны һәм капиталь төзелеш объектларын план буенча урнаштыру зоналары чикләрен билгели торган линияләр күрсәтелгән территорияне планлаштыру сызымы фрагментын әлеге үзгәрешләргә 1 номерлы кушымта нигезендәге редакциядә бирергә.

7. Борылыш нокталары координаталары булган кызыл линияләр күрсәтелгән территорияне планлаштыру сызымы фрагментын әлеге үзгәрешләргә 2 номерлы кушымта нигезендәге редакциядә бирергә, әлеге үзгәрешләргә 3 номерлы кушымта нигезендә билгеләнә торган кызыл линияләрнең характерлы нокталары координаталары исемлеген өстәргә.

___________________________

Казан шәһәре Башкарма комитетының
2011 елның 9 мартындагы
933 номерлы карары белән расланган
«Җиңү паркы» районы территориясен
планлаштыру проектына кертелә
торган үзгәрешләргә
1 номерлы кушымта

Фрагмент чертежа планировки территории с указанием красных линий, линий, обозначающих дороги, улицы, проезды и границ зон планируемого размещения объектов капитального строительства




УСЛОВНЫЕ ОБОЗНАЧЕНИЯ:

- граница территории, в отношении которой осуществляется подготовка внесения изменений
- действующая красная линия
- отменяемая красная линия инженерных сетей
- устанавливаемая красная линия улично-дорожной сети
- линия регулирования застройки
- граница существующего элемента планировочной структуры (квартал)
- К-1 обозначение существующего элемента планировочной структуры
- граница зоны размещения объектов капитального строительства
- граница зоны планируемого размещения объектов капитального строительства
- существующая застройка, подлежащая сносу с целью освобождения территории в установленном законом порядке
- 21 зона размещения улично-дорожной сети
- 1 зона планируемого размещения многоэтажной жилой застройки
- 1 порядковый номер зоны размещения
- 1 вид зоны размещения ОКС
- 1,00 площадь зоны размещения (га)
- 1.1 код вида разрешенного использования
- 10 максимальная общая площадь жилищного фонда (тыс.кв.м.)
- 10 максимальная этажность

Объекты инженерной инфраструктуры*:

- трансформаторная подстанция, план.
- очистные сооружения дождевой канализации, план.

Объекты транспортной инфраструктуры*:

- P объекты хранения и паркирования автотранспорта (муниципальные парковки)

* расположение и количество планируемых объектов инженерной и транспортной инфраструктуры в пределах зон является ориентировочным

Казан шәһәре Башкарма комитетының
2011 елның 9 мартындагы
933 номерлы карары белән расланган
«Җиңү паркы» районы территориясен
планлаштыру проектына кертелә торган
үзгәрешләргә
2 номерлы кушымта

